**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.05.2020 г. Казань № 129

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2010 елның 25 июнендәге 425 номерлы «Республика аттестация-квалификация комиссиясен төзү турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне законнарга туры китерү максатларында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2010 елның 25 июнендәге 425 номерлы «Республика аттестация-квалификация комиссиясен төзү турында» боерыгына (Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2011 елның 5 июлендәге 587 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2010 елның 25 июнендәге 425 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика аттестация-квалификация комиссиясен төзергә (алга таба – Комиссия).»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директорына эшче төркем төзергә.»;

5 пунктта «министр урынбасары А.С.Кондратьевка» сүзләрен «министрның беренче урынбасары Т.Д.Сөләймановка» сүзләренә алмаштырырга.»;

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының «Республика аттестация-квалификация комиссиясен төзү турында» 2010 елның 25 июнендәге 425 номерлы боерыгына 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Т.Д.Сөләймановка йөкләргә.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**

Расланган
Татарстан Республикасы яшьләр
эшләре, спорт һәм туризм
министрлыгының 2010 елның
25 июнендәге 425 номерлы боерыгы
белән (Татарстан Республикасы
яшьләр эшләре министрлыгының
2020 елның 7 нче маендагы
129 номерлы боерыгы редакциясендә)

## Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү хезмәткәрнең һөнәри компетентлыгы дәрәҗәсенең биләгән вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен билгеләү, белем дәрәҗәсен күтәрү һәм аны үстерүне стимуллаштыру, һөнәри бурычларны үтәгән өчен шәхси җаваплылыкны арттыру максатларында гамәлгә ашырыла.

1.2. Аттестациянең төп принциплары булып тора:

белгечләр өчен беренче һәм югары квалификация категориясенә һәм җитәкче хезмәткәрләр өчен югары квалификация категориясенә аттестациянең иреклелегe;

җитәкче хезмәткәрләрне һәм җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затларны беренче квалификация категориясенә аттестацияләүнең мәҗбүрилеге;

аттестацияләнүче хезмәткәрләргә карата объектив, гуманлы һәм дустанә мөнәсәбәт тәэмин итә торган ачыклык һәм коллегиальлек.

1.3. Квалификация категорияләре хезмәткәрләргә биш елга бирелә. Квалификация категориясенә Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте учреждениеләрендә эшләүче затлар кертелә.

1.4. Соңгы ел дәвамында хезмәткәр квалификация категориясен раслау өчен аттестация үтәргә мөмкин. Югыйсә, квалификация категориясенең гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң, хезмәткәр үзенең квалификация категориясен югалта.

### II. Аттестация-квалификация комиссиясе

2.1. Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен барлык категорияләргә дә аттестацияләү Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгының

аттестация-квалификация комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан уздырыла, аның составына так сандагы кеше күләме керә.

2.2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2008 елның 28 ноябрендәге 678 номерлы «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәсен раслау турында» боерыгына (яшьләр эшләре буенча органнар учреждениеләре хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикасы бүлеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 11 июлендәге 563 номерлы «Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 665 нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына һәм әлеге нигезләмәгә таяна.

2.3. Комиссиянең бурычлары булып тора:

хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәләрен гомумиләштерү, эксперт бәяләренең объективлыгын тәэмин итү;

хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсенең билгеләнгән квалификация категориясе таләпләренә туры килүен билгеләү;

аттестацияләнүче хезмәткәрләргә квалификация дәрәҗәләре һәм хезмәт нәтиҗәлелеге нигезендә квалификация категорияләре бирү;

норматив база һәм һөнәри этика нормаларына туры китереп, хезмәткәрне аттестацияләүне үткәрү тәртибен үтәү.

2.4. Комиссиянең персональ составы, аның эш регламенты Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы боерыгы белән раслана.

2.5. Үткәрелгән аттестация нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан һәр хезмәткәргә карата түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

күрсәтелгән квалификация категориясенә туры килү-килмәүне танырга (тиешле квалификация категориясен расларга);

тиешле квалификация категориясен бирергә;

күрсәтелгән квалификация категориясенә туры килмәүне танырга, тиешле квалификация категориясен бирмәскә (квалификация категориясен төшерергә, квалификация категориясен киметергә, элекке квалификация категориясен саклап калырга).

2.6. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

Комиссия карары утырышта катнашучы әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссиянең һәр әгъзасы тавыш биргәндә бер

тавышка ия. Тавышларны тигез бүлгән очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

2.7. Хезмәткәр игълан ителгән квалификация категориясенә туры килми дип танылган очракта, хезмәткәр гаризасы буенча кабат аттестация бер елдан да ким булмаган вакыт дәвамында башкарыла.

2.8. Аттестация нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аттестация кәгазенә кертелә, ул ике нөсхәдә төзелә һәм аттестацияләнүчегә тавыш биргәннән соң ук хәбәр ителә.

Бер экземпляр аттестация кәгазе хезмәткәрнең шәхси эшендә саклана, икенчесе аттестацияләнүчегә бирелә.

Беркетмәгә тавыш бирүдә катнашкан рәис (рәис урынбасары), секретарь һәм комиссия әгъзалары кул куя. Комиссия беркетмәләре кимендә биш ел саклана.

2.9. Комиссия карары Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлгә ашырыла.

## III. Аттестация үткәрү тәртибе

3.1. Аттестация хезмәткәрләрнең эш нәтиҗәләрен анализлау, хезмәткәрнең квалификация дәрәҗәсен, һөнәри компетентлыгын, эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын эксперт бәяләве нигезендә үткәрелә.

3.2. Белгечләрне беренче һәм югары квалификация категориясенә һәм җитәкчеләрне югары квалификация категориясенә аттестацияләү өчен нигез булып хезмәткәр гаризасы тора (нигезләмәнең 1 нче кушымтасы).

3.3. Җитәкче хезмәткәрләрне һәм җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затларны беренче квалификация категориясенә мәҗбүри аттестацияләүне уздыру өчен турыдан-туры җитәкче тәкъдим итүе (нигезләмәнең 2 нче кушымтасы) нигез булып тора.

3.4. Аттестацияләнүче һәр кешегә билгеләнгән үрнәктәге аттестация кәгазе тутырыла (нигезләмәнең 3 нче кушымтасы).

3.5. Квалификация категорияләрен алу һәм күтәрү өчен квалификация күтәрү курсларын узу мәҗбүри шарт булып тора.

3.6. Элек билгеләнгән квалификация категориясе беткәнче аттестациягә тапшырылган һәм комиссиянең уңай карарын алмаган хезмәткәрләр өчен квалификация категориясе аның гамәлдә булу вакыты чыкканчы саклана.

3.7. Хезмәткәрнең яшьләр сәясәте учреждениеләре кысаларында башка вазыйфага күчкәндә, аның артыннан элегрәк бирелгән категория, әгәр ул эшчәнлек профиленә туры килсә, саклана.

3.8. Квалификация категориясен биргәндә эзлекле рәвештә киләсе тәртип үтәлергә тиеш: беренче, югары квалификация категорияләре.

Беренче квалификация категориясе бирелә:

югары һөнәри белемгә ия һәм аттестация үтәргә теләгән вазыйфа буенча кимендә өч ел стажы булган, яки урта һөнәри белемгә ия һәм вазыйфада кимендә биш ел эш стажы булган хезмәткәрләргә.

Югары квалификация категориясе бирелергә мөмкин:

югары һөнәри белеме һәм вазыйфада кимендә биш ел эш стажы булган хезмәткәрләргә.

3.9. Эш профиле буенча кандидатның яисә фән докторының гыйльми дәрәҗәсе булган хезмәткәргә, учреждение җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә квалификация сынаулары узмыйча, беренче һәм югары квалификация категорияләре бирелә.

3.10. Квалификация категориясен бирүгә чираттагы аттестациядән өч яшькә кадәрге балалары булган йөкле хатын-кызлар һәм аналар азат ителә. Аларны яңадан аттестацияләү вакыты, шуңа бәйле рәвештә, күчерелә һәм аттестация эшкә чыкканнан соң бер елдан соң үткәрелә.

3.11. Җитди сәбәп булган очракта (командировкалау, вакытлыча эшкә сәләтсезлек, укучы ялы) хезмәткәрләрнең аттестация срогы учреждение җитәкчесе тәкъдиме буенча күчерелә.

## IV. Аттестация процедураларының этаплылыгы һәм исемлеге

4.1. Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү ике этаптан тора.

Беренче этапта (читтән торып) аттестация материалларын бәяләү башкарыла:

документлар пакеты: гариза, аттестация кәгазе, характеристика/эш урыныннан тәкъдим итү, квалификация күтәрү курсларын узу турында документ, белем алу турында дипломнар, сертификатлар, таныклыклар;

һөнәри эшчәнлекнең гамәли нәтиҗәләре (бастырып чыгарылган мәкаләләр, конференцияләр тезислары, һөнәри эшчәнлек профиле буенча методик эшләнмәләр, авторлык программалары, эшләнмәләр һәм башка материаллар).

Аттестациянең икенче этабында аттестацияләнүче хезмәткәрнең һөнәри белемнәрен бәяләү гамәлгә ашырыла.

4.2. Аттестациянең икенче этабы кысаларында соңгы ике елда һөнәри эшчәнлек турында халык алдында иҗади отчет үткәрелә.

4.3. Игълан ителгән квалификация категориясен бирү турындагы карар хезмәткәрнең аттестациянең ике этабын уңышлы үтүе очрагында кабул ителә.

4.4. Һәр аттестация чорына аттестациянең беренче һәм икенче этапларын оештыру тәртибе Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы боерыгы белән раслана.

4.5. Һөнәри эшчәнлек турында халык алдында иҗади отчет турыдан-туры аттестация комиссиясе утырышында гамәлгә ашырыла.

## V. Аттестациянең гадиләштерелгән процедуралары

5.1. Комиссия карары буенча аттестациянең гадиләштерелгән процедуралары, аттестацияләнүче хезмәткәрне аттестациянең икенче этабында югары квалификация категориясенә эксперт бәясеннән тулысынча яки өлешчә азат итүне күздә тотып, түбәндәге затларга карата кулланыла:

- бүләкләү елына карамастан, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм ведомство бүләкләре булган яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләре;
- аттестация алдыннан соңгы 5 ел дәвамында узган аттестацияләнүче хезмәткәр эшчәнлеге һәм авторлык проектлары/программалары конкурслары буенча халыкара һәм федераль һөнәри конкурслар призерлары, дипломантлары, лауреатлары;
- тәрбияләнүчеләрне, аттестация алдыннан 5 ел дәвамында узган халыкара, бөтенроссия конкурслары, фестивальләре призерларын, җиңүчеләр коллективлары әзерләгән педагогик хезмәткәрләр;

хезмәткәрнең бүләкләр һәм исемнәр алуны раслаучы документлары булганда.

5.2. Беренче квалификация категориясенә аттестация узганда аттестациянең икенче этабында эксперт бәясеннән азат ителәләр:

- Россия Федерациясе спорт, туризм һәм яшьләр сәясәте министрлыгының, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының, бүләкләү елына карамастан, ведомство күкрәк билгеләре һәм мактау грамоталары белән бүләкләнгән хезмәткәрләр;
- аттестация алдыннан соңгы биш ел дәвамында узган аттестацияләнүче хезмәткәр эшчәнлеге профиле буенча республика һөнәри конкурслары һәм авторлык проектлары/программалар конкурслары призерлары, дипломантлары, лауреатлары;
- аттестация алдыннан 5 ел дәвамында узган республика конкурсларында җиңүчеләрне һәм призерларны әзерләгән педагогик хезмәткәрләр;

хезмәткәрнең бүләкләр һәм исемнәр алуны раслаучы документлары булганда.

## VI. Комиссия карарларын тормышка ашыру. Аттестация белән бәйле хезмәт бәхәсләрен карау

6.1. Комиссия утырышыннан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгының боерыгы белән хезмәткәргә квалификация категориясен бирү турында комиссия карары рәсмиләштерелә.

6.2. Хезмәт өчен түләүнең тиешле дәрәҗәсен билгеләү Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы боерыгына кул куйган көннән гамәлгә ашырыла.

6.3. Аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләре бирелгән хезмәткәрләргә хезмәт кенәгәсенә тиешле язма кертелә.

6.4. Аттестациягә бәйле хезмәт бәхәсләре хезмәт бәхәсләрен карау тәртибе турындагы закон нигезендә карала.

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта
Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгының республика аттестация комиссиясенә

_________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________

(вазифасы, эш урыны)

**Гариза**

Мине 20___ елда___________________________вазыйфасы буенча ______________________________ _____________________________квалификация категориясенә аттестацияләвегезне сорыйм.

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе турындагы нигезләмә белән таныштым.

Квалификация категориясе булу, аның гамәлдә булу срогы ________________________________________________________________________

Гаризада күрсәтелгән квалификация категориясенә түбәндәге нәтиҗәләрне аттестацияләү өчен нигез дип саныйм:

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Үзем турында түбәндәге мәгълүматларны җиткерәм:

База белеме, өстәмә белем (белем бирү оешмасының тулы исеме, уку елы, алган белгечлек һәм квалификация)__________________________________________ _______________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

белгечлек буенча эш стажы __________ ел,

әлеге вазыйфада эш стажы ______________ ел,

бу учреждениедә эш стажы ____________ел,

бүләкләр, исемнәр, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем булу

_____________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________

Квалификация күтәрү турында мәгълүмат

_____________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

«___»___________ 20__ имза ________________

Ой телефоны номеры: ________________ эш телефоны:________________